| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА | | ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

№ __________

П Р И К А З                                        Б О Е Р Ы К

«_____»_____________20__

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында**

Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгаруның “Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.07.2002 № 426 карары белән расланган кагыйдәләренең 20 пункты, Кайнар су белән тәэмин итүче, салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су җибәреп торучы оешмаларның инвестицион программаларын әзерләүнең, раслауның һәм корректировкалауның “Су белән тәэмин итү һәм су җибәреп тору өлкәсендә эшчәнлек белән шөгыльләнүче инвестицион һәм җитештерү программалары турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29.07.2013 № 641 карары белән расланган кагыйдәләренең 36 пункты нигезендә **к а р а р б и р ә м :**

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт теркәвенә алынырга тиешле түгел дип танылган актларын, шулай ук Министрлыкның дәүләт теркәвенә алынырга тиешле булмаган, кайнар су белән тәэмин итүче, салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су җибәреп торучы оешмаларның инвестицион программаларын раслаучы, шулай ук әлеге программаларны корректировкалаучы бүтән актлар “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары актлары җыелмасы” журналында бастырып чыгарылырга тиешле дип билгеләргә.

2. Министрлыкның әлеге Боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән

актлары, үз көченә керүнең бүтән срогы билгеләнмәгән булса, аларны бастырып чыгару датасыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән актларны әзерләүче структур бүлекчәләр башлыклары, юридик бүлек белән килештереп, аларны “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары актлары җыелмасы” журналында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә тиеш.

4. Юридик бүлек (Латыпова Э.Ю.) әлеге Боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрерүне тәэмин итәргә тиеш.

5. “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт теркәвенә алынырга тиешле түгел дип танылган актларын бастырып чыгару турында” 22.05.2003 № 201/о Министрлык карарының үз көчен югалтуын танырга.

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Министр** **И.Ә. Фәйзуллин**